ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КАЧЕЛИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Центральная, д. 200, с.Качелино,
Арский муниципальный район, 422013

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КӘЧЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Үзәк урам, 200 йорт, Кәче авылы,
Арча муниципаль районы, 422013

Тел. (84366)52-3-93, факс (84366)52-3-93. E-mail:Kach.Ars@tatar.ru

**КАРАР**

**«02» февраль 2023 ел** **№ 3**

**«Кәче авыл җирлеге муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибе турында» Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 № 18 карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, «Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Кәче авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлешендә) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Кәче авыл җирлеге Советының 08.08.2022 №56 карары нигезендә, 15.11.2022 №1, 16.11. 2022 №2, 17.11. 2022 №3, җыеннарда кабул ителгән карарларны гамәлгә ашыру максатларында, Кәче авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салымы чараларын җыю тәртибе турында» Кәче авыл җирлеге башкарма комитетының 23.12.2022 ел 18 номерлы карары белән расланган Арча муниципаль районы «Кәче авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 һәм 4 пунктларны төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (http://arsk.tatarstan.ru) һәм түбәндәге адреслар буенча гражданнар күпләп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә: ТР, Арча районы, Кәче авылы, Үзәк ур., 200 йорт; ТР, Арча районы, Чулпан авылы, Гагарин ур., 7а йорт. ТР, Арча районы, Якты-Көн авылы, Якты ур., 30а йорт.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Кәче авыл җирлеге башлыгы Р.Р. Гараев

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАЧЕЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ